Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 28 2016 елның 3нче октябре

**«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегендә шәхси торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең чик күләмнәре турында»2016 елның 5 апрелендәге 20 номерлы Яңа Кармәт авыл җирлеге советы карарын гамәлдән чыгару хакында**

Аксубай районы прокурорының 22.09.2016 ел №02-08-02-16Г протестын үтәү йөзеннән Россия Федерациясе Җир кодексының 11.9 статьясының 1 өлеше нигезендә, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 30 статьясының 3 өлешендәге 3 пунктына ярашлы рәвештә, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 30 статьясының 6 өлешендәге 2 пункты нигезендә җир тиешле территориаль зона чикләрендә урнашкан капиталь төзелеш участоклары һәм объектлары җир участокларының чик үлчәмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрлары күрсәтелә, Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советы Карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегендә гражданнарга шәхси торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелә торган җир кишәрлекләренең чик күләмнәре турында» 2016 елның 5 апрелендәге 20 номерлы яңа Кармәт авыл җирлеге Советы карары гамәлдән чыгарылсын
2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Яңа Кармәт авыл
җирлеге башлыгы: И.Р.Шакиров